«Гражданнарның үзара салым акчаларыныд юнәлешен үзгәртү һәм куллану турында» 2023 елның 19 июнендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең Дәвеш авылында гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә “Дәвеш авыл җирлегенең Дәвеш авылын төзекләндерү “Сез Дәвеш авылының Ленин урамыннан Мәгариф урамына кадәр тыкрыклардагы юлларны бетон өслек кулланып ремонтлау өчен каралган 600 000 сум күләмендәге 2023 ел өчен җыелган үзара салым суммасының бер өлешен Дәвеш авыл җирлегенең Дәвеш авылын төзекләндерү, МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу өчен юнәлдерү белән килешәсезме? “Әйе”, “Юк” дигән мәсьәлә буенча 2023 елның 19 июнендә Дәвеш авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 246 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 132 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 132 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең Дәвеш авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

2. “Сез Дәвеш авылының Ленин урамыннан Мәгариф урамына кадәр тыкрыклардагы юлларны бетон өслек кулланып ремонтлау өчен каралган 600 000 сум күләмендәге 2023 ел өчен җыелган үзара салым суммасының бер өлешен Дәвеш авыл җирлегенең Дәвеш авылын төзекләндерү, МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу өчен юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Дәвеш авыл җирлеге Башлыгы Т.Т. Хөсәенов